**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.07.2024 № 759

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен су белән тәэмин итү һәм юынтык суны түгү схемасын раслау турында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәре территориясендә су белән өзлексез тәэмин итүне һәм юынтык суларны агызып җибәрүне җайлау максатларында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Су белән тәэмин итү һәм юынтык суны агызып җибәрү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм суны агызып җибәрү схемалары турында» 2013 елның 05 сентябрендәге 782 номерлы карары (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024-2033 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен су белән тәэмин итү һәм юынтык суны агазып җибәрү схемасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Нурлат шәһәрен су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу схемасын раслау турында» 2014 елның 15 сентябрендәге 12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: htth://pravo.tatarstan.ra, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: https://nurlat.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин